СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

1 ФЕВРАЛЬ, 1997ел. ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 12 (8023) | Бәясе билгеләнгәнчә.

*Районыбыз хәбәрләр тормышыннан*

## Яңа оешманың исеме - «Норлатгаз»

**Тәфсилләп**

***«Норлатгаз» эксплуатация - производство идарәсе төзелү яңа елның зур вакыйгаларыннан берсе булды. Яңа оешманың бурычлары һәм эшләре турында безнең хәбәрчебез аның җитәкчесе Владимир Васильевич БОГАТИКОВ белән әңгәмә корды.***

- Районыбызда газлаштыру эшләренең күләме кискен арту сәбәпле, «Таттрансгаз» предприятиесе «Лениногорскгаз» эксплуатация - җитештерү идарәсе структурасыннан Норлат газ службасын аерырга ризалык бирде һәм аның базасында яңа идарә төзеде. Бу мәсьәләне хәл итү фәкать район хакимиятенең яңа башлыгы Фатыйх Сәүбән улы Сибагатуллинның тырышлыгы белән генә мөмкин булды.

Ә мондый предприятиене оештыру зарурлыгы күптән килеп туган иде. Районыбызда газүткәргечләр саны елдан - ел арта бара һәм бүген аларның гомуми озынлыгы 332 километрга җитте инде. Газлаштырылган промышленность, социаль - көнкүреш, коммуналь бәгъланышлы объектлар һәм торак йортлар саны арткannan арта бара. Моңарчы гамәлдә булган газ службасында исә аларның барысына да нормаль хезмәт күрсәтү өчен ни техник, ни кеше ресурслары юк иде.

**- Яңа коллектив нинди производство программасын хәл кылырга тиеш булачак?**

- Беренче чираттагы бурыч булып шәһәрне һәм авылларны газлаштыру эшен тизләтү кала. Аннан соң газүткәргечләрне, газ ягып эшли торган җиһазларны эксплуатацияләү һәм аларга хезмәт күрсәтүнең куркынычсызлыгы мәсьәләсе дә барчабызны борчый һәм бу шулай ук безнең вазифага керә. Без моннан тыш промышленность преприятиеләре һәм гражданнарның шәхси файдалануындагы объектларга техник хезмәт күрсәтүне яхшырту өстендә дә эшләячәкбез. Якын киләчәктә барлыгы 19705 , шул исәптән авыл җирендә 10751 фатирга газ кертү һәм 2000нче елга кадәр тагын 300 километр газүткәргеч тарту бурычы тора. Боларның барысын башкарып чыгуны тәэмин итү өчен беренче чиратта хәзерлекле һәм квалификацияле кадрлар, яңа техника һәм җиһазлар кирәк. Белгечләрне «Таттрансгаз»ның укыту комбинатында әзерләячәкбез.

Күргәнегезчә, яңа оешма алдында торган эшләр гаять күп әле.

## ЮБИЛЕЙ УҢАЕННАН

Узган атнада Казандагы оборона - спорт - техника оешмасы өлкә комитетында оборона - спорт - техника оешмасы (ОСТО, элеккеге ДОСААФ) оешуга 70 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды. Анда безнең районнан да вәкилләр катнашты.

ОСТОның район комитетында да әлеге юбилей уңаеннан тантаналы җыелыш булып узды. Анда оешма ветераннары, аның эшчәнлегендә актив катнашучы белгечләр, укытучылар катнашты.

## *Хезмәтләре белән мактаулылар*



Кемгә кемгә, ә менә токарь өчен хуҗалыкта һичкайчан эш бетми. Мөһим кампанияләр чорында эшен тәмамлап тынычлап өенә кайтып китә алмый ул: техника тирәсендә берәр чатаклык килеп чыкса, янә станогы артына басарга туры килә. Сафтан чыккан узел урынына җиңел генә яңасын урнаштыра торган вакыт түгел шул хәзер.

Алексей Яллин - токарь. Хуҗалык механизаторларының аңа мөрәҗәгать итмәгән көне сирәк. Алексей Иванович исә бер генә үтнечне дә кире какмый, һәркемгә кулыннан килгәнчә ярдәм итә. Әле менә техниканы язгы кыр эшләренә хәзерләү чорында да Яллин көне буе үзәк ремонт мастерскоенда. Язын сынатмыйм дисәң, бүген тырышырга кирәк, ди ул.

**Рәсемдә: Хафизов исемендәге КФХА токаре А.Яллин.** **Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## КАЗАНДА МЕТРО БУЛАЧАК

(Татар - информ). 25 гыйнварда Татарстан Министрлар Кабинетында Казанда метро төзү мәсьәләләренә багышланган киңәшмә булды. Анда министрлык, шәһәр һәм район хакимиятләре, Россиянең метро төзү һәм проект оешмалары җитәкчеләре катнашты.

Киңәшмәдә рәислек иткән Татарстан Республикасы Премьер - министры Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, бу - алдагы ун еллыкларга республикадагы иң зур төзелеш булачак.

Татарстан башкаласында гомуми озынлыгы 43 километр булган 3 линия төзү күздә тотыла. Бүгенге беренче чираттагы ун чакрымлы бүлемтекнең техник проекты эшләнгән һәм расланган. Ул 8 елдан соң үтәләчәк. Быел акчаны шәһәрнең төзелеш индустриясенә җибәрү планлаштырыла. Бу - җыелма тимер - бетон эшләп чыгару, казу җиһазлары сатып алу, трассаны әзерләү өчен кирәк. Станцияләр ачык ысул белән корылачак. Шуңа күрә урамнарны ябып торырга, шәһәр транспортының маршрутларын үзгәртергә туры киләчәк.

Үзебезнең белгечләр булганчыга кадәр метро төзүчеләр башка шәһәрләрдән чакырылачак.

## *Җылы кышын гына кадерле шул*

**Шәһәрдә кыш уртасында шулкадәр гаиләнең җылысыз калганын күптән хәтерләмиләр инде. Кызганычка каршы, МСО котельнясыннан җылытыла торган күпкатлы һәм коттедж тибындагы йортларда торучылар бу атнада менә шундый язмышка дучар ителделәр. Дөрес, котельняда казаннар төзек һәм ягыла торганнары эшләп тора, ә менә җылылык трассаларында җитди сафтан чыгулар килеп чыгу сәбәпле йортларга җылы бирүне туктатып торырга туры килде. Хәзер хәлнең сәбәпләренә керешеп торыр чак түгел,иң әһәмиятлесе - МСОның үз көчләре һәм шәһәрнең башка оешмаларыннан ярдәмгә күтәрелгән бригадалар авария нәтиҗәләрен ничек тә тизрәк юк итеп, җылы бирүне нормальләштерү өстендә көне - төне эшлиләр.**

**Кичә төш алдыннан күпкатлы йортлар микрорайонына бара торган трассаның «бөҗрасын» худка җибәрү өчен чаралар төгәлләнеп килә инде,шуннан соң чиратлап йортларга да җылы бирә башларга мөмкин булачак, диделәр авария нәтиҗәләрен төзәтү эшләренә җитәкчелек итүчеләр. Шулай гына була күрсен.**

## РАЙОН ПРОМЫШЛЕННОСТ[Е] УЗГАН ЕЛДА

### *(икътисадый күзәтү)*

Статистика бүлеге мәгълүматларыннан күренгәнчә, былтыр район промышленносте аннан алдагы елдагыдан начар эшләгән диеп булмый. Җитештерелгән продукция чагыштырма бәяләрдә 687 миллиард 567 миллион сумлык, ягъни 1995 елда эшләп чыгарылганнан 5,1 процентка артыграк булган. Шулай итеп, былтыр промышленость продукциясе җитештерүне арттыруның республика күләмендә куелган дәрәҗәсенә ирешкән булып чыгабыз. Әмма тулай продукциянең зур өлеше - узган ел 84 проценты «Норлатнефть» нефть - газ чыгару идарәсе өлешенә туры килүен билгеләп үтми мөмкин түгел. Бер үк вакытта идарәнең бу юнәлештә 8 процент үсешкә ирешүен дә әйтергә кирәк. ( Сүз уңаеннан әйткәндә, 1996 елда НГДУ җитештергән продукциянең аннан алдагы елдагыдан арткан өлеше генә дә былтыр ит һәм сөт - май комбинатлары икесе бергә яки шикәр заводы үзе генә җитештергән барлык продукция күләме кадәр. Шулай булгач, район икътисадының, шул исәптән бюджетның да беренче чиратта кемнәр җилкәсендә икәнлеге аңлашыла торгандыр).Дөрес, бу гына башка предприятие һәм оешмаларның әһәмиятен һич тә киметми, чөнки аларның һәркайсы үз урынында бик кирәк һәм тормышыбыз алардан башка мөмкин булмас иде. Шикәр заводы былтыр 51748 тонна шикәр комы эшләп чыгарган, ит комбинаты 1774 тонна ит һәм 163 тонна казылык әйберләре биргән (соңгысы 1995 елдагыдан 23 тоннага артыграк), сөт - май комбинатының куе сөт продукциясе 1841 тонна булган (аннан алдагы елдагыдан 50 тоннага күбрәк), элеватор 21 мең тонна чамасы катнаш азык җитештергән ( еллык үсеш 23 процент), икмәк заводы 1480 тонна икмәк - күмәч чыгарган (25,3 процентка кимрәк). Продукциясе ашамлык әйберләре рәтенә кермәсә дә, былтыр типографиянең бланклар басуны аннан алдагы елдагыдан икеярым тапкырга арттыруга ирешүен, шулай итеп, тулай продукциянең еллык күләмен 1995 елгы дәрәҗәдән күбрәк булуын әйтми мөмкин түгел.

Тулаем алганда, былтыр ун предприятиенең бишесе продукциянең гомуми күләмен арттырды, калганнары чигенеш ясады. Иң зур үсеш урман хуҗалыгында булды (17,3 процент), ә иң зур чигенеш икмәк заводында (23,1 процент) һәм Төрнәс эшкәртү предприятиесендә (40,2 процент). Шулай итеп, абсолют саннарда район промышленностеның үсеше 33 миллиардтан аз гына артыграк булды. Ә бит әлеге биш предприятие 1995 елгы дәрәҗәдә генә эшләгән булса да нәтиҗәләр никадәр югары булган булыр иде.

Бер үк вакытта җитештерелгән һәм реализацияләнгән продукция күрсәткечләрендә дә уйланырлык аерма бар. НГДУ, типография һәм ит комбинатының җитештергән һәм кулланучыларга озатылган продукция күләмнәре арасында аерма булмаса, сөт - май комбинатында, машина төзү заводында һәм Төрнәс спирт заводында шактый продукция складта калган. Ә продукция сатылмагач, хезмәт хакы, төрле салымнар түләү дә тоткарлана дигән сүз. Дөрес, беренчесенә килгәндә, былтыр промышленностьта эшләүчеләрнең айлык уртача хезмәт хакы 1 миллион 37 мең сум булды һәм бу - районда гы җитештерү белән бәйле барлык тармаклар арасында да иң югарысы. Тагын шунысы да бар, промышленность предприятиеләрендә хезмәт хакы буенча бурыч бер эшләүчегә күчереп исәпләгәндә ел ахырына 350 мең сум тирәсе генә иде.

Ә район икътисадының башка тармакларында еллык эш нәтиҗәләре турында сүз аерым.

## Яңа расписание буенча

Редакциягә Норлат станциясе аша уза торган поездларның расписаниесе үзгәргән икән, шул хакта газетада хәбәр итмәссез микән дип шалтыратучылар күп бу арада. Шуны истә тотып без вокзал җитәкчелегенә мөрәҗәгать иттек һәм менә нинди җавап алдык:

Февральдән 233/234 нче Яр Чаллы - Мәскәү һәм 619/620 нче Ульяновск - Яр Чаллы поездлары расписаниесенә үзгәрешләр кертелә. Яр Чаллыдан килүче 233 нче поезд 4 февральдән безнең станция аркылы көнаралаш, җөп көннәрдә, әмма элеккеге расписание буенча,иртәнге 4 сәгать 33 минутта узачак. Ә менә Мәскәүдән килүче 234 нче поезд 6 февральдән җөп көннәрдә көндезге 11 сәгать 17 минутта булачак. 620 нче Ульяновск - Яр Чаллы поезды 3 февральдән так көннәрдә 0 сәгать 42 минутта килә башлаячак, ә 619 нчы Яр Чаллы - Ульяновск поезды 7 февральдән шулай ук так көннәрдә, иртәнге 9 сәгать 28 минутта була. Җәйге расписаниегә күчкәнчегә кадәр ул Ульяновскига 15 сәгать 7 минутта килеп җитә.

Сәфәрегез хәерле булсын!

## Мәчет ачылу тантанасына чакырабыз

Хөрмәтле райондашлар, кадерле якташлар!

1997 елның 3 февралендә Төрнәстә авыл тарихында беренче мәчетне тантаналы төстә ачу була. Районыбызның хак мөселманнарын, якташларыбызны һәм теләге булган барча кешене безнең бу шатлыгыбызны уртаклашырга килергә чакырабыз.

Мәчет ачу тантанасы иртәнге сәгать 10да башлана.

## Терлекчелек - көнүзәк өлкә

# ӨЙРӘНҮ ФАЙДАГА КИТСЕН

Бүген хуҗалыкта салкын ысул белән асрау өчен ясалган читлеккә беренче бозауны чыгардылар. Яңа гына дөньяга килгән яшь бозау ятсынган кеше сыман яңа урынга текәлеп - текәлеп карады да борынын салам стенага төртеп тынып калды. Ошатты бугай урынны. Ә урын, чыннан да, ошатмаслык түгел иде. Пресслангaн салам белән бүленгән, өр - яңа такта ишекләре белән ялтырап торган 30 читлек бозауларны кабул итәргә әзер иде инде.

- Бозауларыбыз, сөбханалла, көр, матур туалар. Әнә әүвәл алган 79сы да матур гына үсеп киләләр. Инде салкын методка тагы да зуррак ышаныч багълыйбыз,- ди ассоциация рәисе В.Сатдаров. - Ә терлекчеләребезне эшкә өйрәтеп торасы юк, күбесе тәҗрибәлеләр.

Рәис соңгысын мактанып түгел, горурланып әйтә. Әле генә үткән авыл хуҗалыгы алдынгылары слетында бозау караучы Фәүзия Вәлитова 750 грамм тәүлеклек үсеш алып район буенча II нче урынга чыкты. Терлекчелектә күрше «Рассвет» тагы апасы, атаклы Гөлсирә Мусина кебек уңган - булдыклы дигән данны нык тотарга жыена Фәүзия. Өстәвенә, авыру ире, әнисен дә рәнҗемәслек итеп карарга өлгерә, шуңа халык бик ихтирам итә үзен.

Озак еллар таналар караучы Гыйззәтуллиннар исеме дә Якты Күл чиген күптән узган. Ибраһим ага белән Хәниф ага җәй көннәрендә 150 баш тананы бергәләп көтәләр, ә кыш көннәрендә симертүдә эшлиләр иде. Былтыр



Хәниф ага октябрь аенда вафат булды (урыны җәннәттә булсын), үзләренә аталган хөрмәтләрне күрмичә калды. Юкса, зур җиңүгә ирешкән иделәр алар: тәүлеклек үсешне 1100 граммга җиткереп, район терлекчеләре арасында беренче урынга чыктылар. Әтисе урынына бүләк алырга улы Илназ чыкты. Аның моңа хакы да бар иде: берничә ел инде ул җәйләрен шулай ук малларны көтүдә булышып йөри бит.

Хуҗалыкта Фәнис Фәйзуллин хезмәтен дә югары бәялиләр. Яз - җәй - көз буе ул кырдан кайтып керми: Т - 70 белән чөгендер мәйданнарына берүзе чәчү үткәрә, рәт араларын эшкәртә, көзен КС - 6 белән чөгендерне җыя да терлекчелеккә килә. Бер җирдә намуслы эшләргә күнгән кеше кайда да сынатмый икән ул - биредә дә егет эшеннән канәгатьләр.

Сөтчелектә дә Якты күллеләр акрынлап реванш алып киләләр. Бүген Фәридә Дәүләтшина таналар белән эшли, көнгә 10,5әр килограмм сөт сава. Фәридә 8 ел эшли биредә, шул арада икенче тапкыр таналардан группа туплый инде. Аның уңышлы эшләвендә ире Нәфиснең дә өлеше бар, чөнки җәйге чорда механизатор булып эшләгән Нәфис кышын терлекчелеккә килә, Фәридә группасы сыерларына да хезмәт күрсәтә. Миңсылу Хәнәфиева группасында да савым әйбәт. 25 ел буе сыер савучы булып эшләгән терлекче әле дә яшьләрчә җитез, тырыш, алдынгы. Ел башыннан хуҗалык буенча уртача савым да бераз үсте, аны тагы да күтәрү мөмкинлеге барлыгын да яшермиләр хуҗалыкта. Иң мөһиме азык җитәрлек, рацион мул. Сүз шунда җиткәч, алар азык культураларын игүдә күп көч куйган Сәлимҗан Шәриповны зур хөрмәт белән телгә алалар. Ярдәмчесе Алексей Александров белән 600 гектарда азык җыйган ул. Шундый фидакарьләр тырышлыгы белән кышкыга һәр шартлы башка 28,1 центнер исәбеннән азык әзерләнгән. Ә маллар өчен иң мөһиме шул түгелмени? Әлбәттә, Якты Күл терлекчеләренең проблемалары да бар. Ферма биналары иске, кысан. Хуҗалык җитәкчелеге 100 баш малга яңа бина салу хәстәре белән материаллар әзерләп йөри йөрүен, әмма аны аякка бастыруга ай - һай күп көч кирәк булачак әле! Терлекчелектә подряд ысулын кертүдә дә акрынрак исәплиләр. Ә бит кешене ахыр нәтиҗә белән кызыксындырмый, аны хуҗа итми торып чын күрсәткеч булмаячак. (Хуҗалык исәбе, подряд дигән нәрсә Якты Күллеләр өчен чит түгел, «Рассвет» составында булганда алар аның пионерлары иделәр). Якты Күлгә уйланасы, эзләнәсе бар әле.

Күрше районнар тәҗрибәләрен күреп кайту да өстәмә җим бирде аларга. Өйрәнү файдага китсен, эзләнү нәтиҗә бирсен иде дип телисе генә кала.

**С.Хәйруллина.**

**Рәсемдә: Ибраһим Гыйззәтуллин район авыл хуҗалыгы алдынгылары слетында.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Аның горур һөнәре

Надя беренче тапкыр әтисеннән атта йөртүен үтенгәндә аңа әле бары 5 кенә яшь иде. Ул чакта әтисе аңа гаҗәпләнеп карады, әмма аның соравын үтәде. Әтисенең яраткан аты Нальчик кушаматлы иде. Ул аның белән көтү көтте, фермага азык ташыды, ә җәйләрен ат ярышларында катнашты.

... Ул көннәрдән соң 6 еллап гомер үтте. 1996 елның язы җитте. Бу еллар эчендә Надя абыйсы һәм башка үсмерләр белән күнегүләргә йөреп чын - чынлап җайдакка әверелде. Мичурин исемендәге КХА рәисе Ильяс Нургалиевич Мөхәммәтов белән баш зоотехник Мидхәт Җәүдәтович Фәхретдинов аңа нәкъ шул чакта игътибар итәләр дә. Кара син аны, ир - егетләрдән һич калышмый бит! Кызга күнегүләр өчен Сектор кушаматлы яшь атны бирергә хәл итәләр. Надя иртәдән кичкә кадәр мәйданнан кайтып керми. Тренер Николай Ефимов Надяга булыша. Ничек итеп старттан кузгалырга, чапканда ничек үз - үзеңне тотарга, атны ничек куаларга - бу киңәшләрне Надя үзенә сеңдерә бара. Тагы бер нәрсәне нык үзләштерә кыз: ярышларда тыныч, куркусыз булырга, алга да алга гына омтылырга.

... Норлат. Традицион Сабантуй. Ипподромда меңнәрчә кеше.

- Стартка әзерләнергә! - Баш судьяның тавышы янгырый. - Яшь чаптарлар 1600 метрга ярышалар.

Җайдак кыз финишка ул чакта дүртенче булып килде. Әмма бит аның җитди ярышка чыгуы да беренче тапкыр иде, күрәсез, имтиханны узды.

Ә тренировкалар үз чиратында уза тордылар. Надя һәм Сектор бер - берләрен яхшы аңладылар. Җәй көнне аңа Зәй, Түбән Кама, Чаллы, Чистай шәһәрләрендә ат ярышларында катнашырга туры килде һәм һәрвакыт призлы урыннарны яулады. Чистайдагы ярыш аерата истә калырлык булды. Жирәбә буенча ул абыйсы Ваня белән бер заездга туры килде. 2 түгәрәк үтәргә кирәк иде, стартка республиканың 7 иң көчле чаптары басты. Биредә аерата игътибарлы булырга һәм характер күрсәтергә кирәк иде. Финишка 120 метр кала Надя тизлеген нык арттырды һәм Сектор ... беренче килде. Ул ярышта абыйсы икенче булды. Бу инде зур җиңү иде!

Узган көз уныш бәйрәмендә Норлатта Надя шулай ук чыгыш ясады - башта Мировойда II урынны алды, аннан Секторда чапты, янә әйбәт вакыт күрсәтте. Надяның чабышларда катнашуы һәртөрле бүләкләр белән билгеләнде: анда магнитофон да, үтүк тә, кухня комбайны да, чәй сервизы да, матур стена сәгате дә бар иде. Бу - аның көндәлек хезмәте, туктаусыз күнегүләренә, атларга мәхәббәтенә чын бәя. Яшь җайдак турында аның тренеры менә нәрсә ди.

- Надежда бик җыйнак, атны оста иярли. Чабыш темпын сайлауда төгәл, аның көчен финиш ахырына кадәр саклый белә. Бик дисциплиналы. Миңа калса, ул нәкъ үз эше, җаны теләгән эше белән шөгыльләнә.

Моның белән бәхәсләшү кыен.

**Ф.СИДУЛЛИН.**
**Вишневая Поляна авылы.**

## Тирәбездә яхшы кешеләр

## Гомер еллары - байлыгы

50 яшь... Кешенең ярты гасырлык гомере. Бу юлны ул җиңел үткәнме, авырмы - җырда җырланганча еллары - аның байлыгы.

Галимҗан Һадиевичның тормыш юлын мин үзенең суларын еракка еракка, диңгезгә кадәр илтүче тигез агучы елга белән чагыштырыр идем.

Ул гади авыл укытучысы. Шул ук вакытта аны сәнгать кешесе дип кабул итеп тә була. Һәрвакыт матур итеп таралган дулкын - дулкын чәчләре, очкынлы күзләре, фарфор төсле ак тешләрен күрсәтеп елмаеп җибәрүе әңгәмәдәшен аңа гына карап торырга мәҗбүр итә.

Галимҗан Һадиевич аралашучан кеше. Аның ягымлылыгы үзенә һәр дәресне җанлы һәм кызыклы итеп үткәрергә, хәтта «авыр» балалар белән дә җиңел аралашырга мөмкинлек бирә. Ул Яңа Әлмәт урта мәктәбендә 25 елдан артык математика укыта. Коллективта да, авылда да абруе зур. Ә аның укучылары кайда гына эшләмиләр бүген: мәктәптә дә, шифаханәдә дә, колхозда да, производствода да.

Галимҗан Һадиевич зур һәм тату гаиләдә үсте. Аның туганнары нигездә авылда яшиләр. Әнисе Мәрьям апа, әтисе Һади абзый үз балаларына бәхетне читтән эзләмәскә өйрәттеләр. Менә инде Һади абзыйның да безнең арада булмавына 5 ел тулды. Сугыш һәм анда алынган яралар аның гомерен кыскартты. Галимҗан Һадиевич һәм аның хатыны Гөлсәрия ата - аналары турында кайгыртучанлык күрсәттеләр. Алар белән һәрчак бергә яшәделәр. Үзләренең дә балалары өчәү. Өлкән кызлары Гүзәл кияүдә, кызы Әминә үсә. Кечеләре Гөлия 7 нче класста укый. Ә көз уллары Рәис Чечнядан кайтты. Аның Грозныйда булган вакытында күпме кайгы - борчу кичерде ата - ана. Алардан хат - хәбәр булмады. Өенә кайткач та иң элек әнисе янына эшкә ашыкты. Бу очрашу да күз яше чыгарырдай шатлыклы булды!

Яңа елда бу гаиләдә тагын шатлыклы вакыйга булды. Мәрьям апаның оныгының улы Ринат гаиләсендә игезәкләр - Рузил белән Рузилә туды.

Галимҗан Һадиевичны 50 еллык юбилее белән котлап, аңа сәламәтлек, уңышлар телим.

**И.ЯҺУДИНА.**
**Иске Әлмәт авылы.**

## Котлыйбыз!

Якын дустыбыз **Фирдәвес Котдус кызы Хәсәнҗанованы** туган көне белән кайнар котлыйбыз. Аңа озын гомер, нык сәламәтлек,



бәхет, гаиләсенә иминлек телибез.

Без телибез сиңа зур бәхетләр

Күтәренке булсын күңелең

Гөрләп яшә, картаюны белмә

Гел шатлыкта үтсен гомерең.

**Илдус һәм Нурисә Әхмәтовлар.**

## Белдерү

**Чикләнгән җаваплылыктагы «Норлат - Лада» ширкәте ВАЗ - 2101, 2107 двигательләрен капиталь ремонтлауга заказлар кабул итә. Сыйфат гарантияләнә.**

Адрес.: 60 лет Октября ур., «Автосервис», тел.: 2 - 23 - 05.

*Син беләсеңме?*

## БЕРАЗ СТРЕСС ЯРЫЙ УЛ!

Кыска вакытлы киеренке эшләү һәм компьютерда уйнау туйдырган мини - стресс кешенең иммун системасын ялкытмый, ә тереклек сәләтен күтәрә, аның тулаем физик халәтенә уңай йогынты ясый. Лондондагы Вестминстер университеты профессоры Фил Эванс менә шундый расслама белән чыгыш ясады.

Профессор сүзләренә караганда тикшеренүләр барышында ул компьютерда «Язмыш» дип аталган катлаулы уен сеансын башкарганнан соң, мәсәлән, кеше организмында иммун системасының халәтен билдерүче актив антитәнчекләр санының артуын ачыклаган. Мәсәлән, яңа квартирага күчкәндә билгеле вакытта эшләнеп бетәргә тиешле катлаулы эшне эшләү шундый ук йогынты ясый.

«Без кыска вакытлы психологик киеренкелеккә чыдау өчен яхшы җайланган»,- дип саный профессор Эванс. Әлбәттә, инде, хәлне контрольдә тоткан шартларда шулай бу. Мондый очракларда артерил басымы күтәрелә, ләкин иммун системасы моны уңай кабул итә. Элегрәк үткәрелгән тикшеренүләр күрсәткәнчә, сессия вакытында кайбер студентлар ешрак авырый, әмма турыдан - туры имтихан чорында аларның иммун системасы активрак эш итә башлый, дип саный галим.

Эванс сүзләренә караганда, алынган нәтиҗәләр, балаларның компьютерда бертуктаусыз уйнавы, әлбәттә, бөтен авырулардан арыну чарасы була ала, дигәнне аңлатмый. «Бер сәгатьлек шундый уеннан соң иммун системасы нормага кайта», - ди Эванс. Озакка сузылган хроник стресс исә иммун системасын ялкыта.

